БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«05» 09 2023 ел

**КАРАР**

№ 225

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүләргә муниципаль социаль заказ формалаштырганда муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында**

«Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәтләре күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - Федераль закон) 28 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) тарафыннан социаль өлкәдә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру турында карарлар кабул итүгә гомуми таләпләрне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 13 октябрендәге 1678 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне «өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш)»эшчәнлеге юнәлеше буенча Федераль закон нигезләмәләре нигезендә оештырырга.

2.«Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Мәгариф идарәсе»МКУны социаль өлкәдә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру»эшчәнлеге юнәлеше буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә муниципаль социаль заказны раслый торган вәкаләтле орган итеп(алга таба - муниципаль хезмәтләр) билгеләргә.

3.Федераль законның 9 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган муниципаль хезмәт башкаручыларны сайлап алуның конкурентлык ысулыннан файдаланып,балаларга өстәмә белем бирүне финанслау системасын муниципаль берәмлек территориясендә «Мәгариф» милли проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проектын гамәлгә ашыру кысасында «Өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» эшчәнлеге юнәлеше буенча Федераль закон нигезендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль социаль заказ булдыруны һәм үтәүне

тәэмин итәргә.

4. Федераль законның 28 статьясындагы 3 өлешендә һәм 8 статьясында каралган таләпләрне үтәү максатларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында «Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтүләргә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» Федераль закон нормалары кулланыла дип билгеләргә.

5. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ социаль сертификат нигезендә «Өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәт күрсәтүгә муниципаль социаль заказ булдыруны һәм раслауны тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» муниципаль мәгариф оешмалары эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем турындагы Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).

7. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» муниципаль мәгариф оешмалары эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем составын расларга (3 нче кушымта).

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) һәм «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
Җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма
комитетының 2023 елның
«05» 09
225 номерлы карарына
1 нче кушымта

**«Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтүләренә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган хезмәт күрсәтүләрне башкаручыларны сайлап алу ысулы буенча апробация гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәтләр күрсәтү**

**ИСЕМЛЕГЕ**

1. Өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру:

804200О.99.0.ББ52АЕ04000 (техник юнәлешле, уку формасы: көндезге);

804200О.99.0.ББ52АЕ16000 (техник юнәлешле, уку формасы: тормышка ашыруның челтәрле формасын кулланып, көндезге уку;

804200О.99.0.ББ52АЕ28000( табигать фәннәре юнәлеше,уку формасы: көндезге)

804200О.99.0.ББ52АЕ40000 (табигать-фәннәре юнәлеше, уку формасы: тормышка ашыруның челтәрле формасын кулланып, көндезге)

804200О.99.0.ББ52АЕ52000 (физкультура - спорт юнәлеше, уку формасы: көндезге);

804200О.99.0.ББ52АЕ64000 (физкультура-спорт юнәлеше, уку формасы:тормышка ашыруның челтәрле формасын кулланып, көндезге)

804200О.99.0.ББ52АЕ76000 (сәнгать юнәлеше, уку формасы:көндезге);

804200О.99.0.ББ52АЕ88000 (сәнгать юнәлеше, уку формасы: тормышка ашыруның челтәрле формасын кулланып, көндезге)

804200О.99.0.ББ52АЖ00000 (туристик-туган якны өйрәнү юнәлеше, уку формасы: көндезге);

804200О.99.0.ББ52АЖ12000 (туристик-туган якны өйрәнү юнәлеше, уку формасы: көндезге, тормышка ашыруның челтәрле формасын кулланып)

804200О.99.0.ББ52АЖ24000 (социаль - педагогик юнәлешле, уку формасы:көндезге)

804200О.99.0.ББ52АЖ36000 (социаль-педагогик юнәлешле, уку формасы:көндезге,тормышка ашыруның челтәрле формасын кулланып)

2. Сәламәтлеге чикле балалар(ОВЗ) өчен өстәмә гомумүсеш программаларын гамәлгә ашыру.

804200О.99.0.ББ52АН48000 (сәнгать юнәлеше, уку формасы:көндезге);

804200О.99.0.ББ52АН96000 (социаль-педагогик (социаль-гуманитар) юнәлешле, уку рәвеше: көндезге);

804200О.99.0.ББ52АН24000 (физкультура-спорт юнәлеше, уку формасы: көндезге).

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2023 елның «05» 09
225 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» муниципаль мәгариф оешмалары эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем (алга таба - эшче төркем) коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

1.2. Эшче төркем Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының (алга таба - ОМСУ) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә «Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 2.1.өлешенең 3 пунктчасында билгеләнгән эшчәнлек юнәлешләренә туры килгән муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль социаль заказын формалаштыру буенча тәкъдимнәр әзерләгәндә үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында төзелде.

1.3. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» муниципаль мәгариф оешмалары эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем турында Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, башка норматив хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна (алга таба - Нигезләмә).

1.4. Эшче төркемнең утырыш йомгаклары буенча кабул ителгән карарлар тәкъдим итү характерында.

2. Эшче төркемнең бурычлары

Эшче төркемнең бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә 189-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктчасы белән билгеләнгән эшчәнлекнең тиешле юнәлешләре буенча муниципаль социаль заказны формалаштыру һәм раслау буенча тәкъдимнәр әзерләү.

2.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә 189-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә каралган муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру механизмнары апробациясен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

2.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль социаль заказны формалаштырганда һәм үтәгәндә мәгълүмати системалардан файдалану буенча тәкъдимнәр әзерләү.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында күрсәтелгән эшче төркемне төзү максатына ирешүгә юнәлдерелгән башка бурычларны гамәлгә ашыру.

## 3. Эшче төркемнең вәкаләтләре

Әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә күрсәтелгән бурычларны хәл итү өчен, эшче төркем түбәндәге вәкаләтләргә ия:

3.1. Эшче төркем утырышларында эшче төркем компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне карарга.

3.2. Җирле үзидарә органнарыннан һәм муниципаль оешмалардан эшче төркем компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмат соратып алырга.

3.3. Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль оешмалар тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматны, документларны һәм материалларны эшче төркем бурычлары нигезендә карарга.

## 4. Эшче төркем функцияләре

Эшче төркемнең төп функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

4.1. Социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем әгъзаларының тәкъдимнәрен Федераль закон нигезендә карау һәм 189-ФЗ номерлы Федераль законда каралган социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру механизмнарына апробация үткәрү.

4.2. Апробация планын гамәлгә ашыру өчен кирәкле оештыру, методик, технологик чараларны формалаштыру, билгеләү.

4.3. Апробация планын гамәлгә ашыруның барышын агымдагы мониторинглау һәм тикшереп торуны үткәрү.

## 5. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру

5.1. Эшче төркем составы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

5.2. Эшче төркемне эшче төркем җитәкчесе җитәкли. Эшче төркем җитәкчесенең урынбасары бар. Эшче төркем җитәкчесе булмаганда, аның вәкаләтләрен җитәкче урынбасары башкара.

5.3. Эшче төркем җитәкчесе түбәндәге функцияләрне башкара:

эшче төркем эшчәнлеген оештыра;

эшче төркем эшчәнлеген планлаштыра;

эшче төркемнең чираттагы утырышында фикер алышу өчен көн тәртибен раслый;

эшче төркем утырышларын алып бара.

5.4. Эшче төркем утырышлары кирәк саен уздырыла.

5.5. Әгәр анда эшче төркем әгъзаларының кимендә яртысы катнашса,эшче төркем утырышы вәкаләтле дип санала.

5.6. Эшче төркем эшчәнлеген документлар белән тәэмин итү эшче төркем сәркатибе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.7. Эшче төркем сәркатибе:

5.7.1. эшче төркем утырышларын әзерләүне һәм оештыруны гамәлгә ашыра;

5.7.2. эшче төркем карарлары проектларын әзерләүне гамәлгә ашыра;

5.7.3. эшче төркемнең утырышлар беркетмәләрен алып бара һәм проект комитетының беркетмә карарларының үтәлешен тикшереп тора;

5.7.4. эшче төркем утырышлары нәтиҗәләре буенча мәгълүмат материалларын, документларны гомумиләштерә һәм әзерли;

5.8. Эшче төркем карары кабул ителгән дип санала, әгәр дә аның өчен эшче төркем әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә. Тавышлар тигез булганда, эшче төркем җитәкчесе яисә эшче төркем җитәкчесе урынбасарының, эшче төркем җитәкчесе вазыйфаларын башкаручының тавышы хәлиткеч булып тора.

5.9. Эшче төркем карары эшче төркем утырышы беркетмәсе (алга таба - беркетмә) белән рәсмиләштерелә, аңа эшче төркем җитәкчесе яисә эшче төркем рәисе вазыйфаларын башкаручы эшче төркем җитәкчесе урынбасары имза сала.

Беркетмәләрнең күчермәләре эш төркеменең барлык әгъзаларына җибәрелә.

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2023 елның «05» 09 225 номерлы карарына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» муниципаль мәгариф оешмалары эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эш төркеме составы

| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфасы |
|---|---|
| Эшче төркем җитәкчесе | |
| Мөхәрләмов Р.К. | МКУ «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» башлыгы |
| Эшче төркем җитәкчесе урынбасары | |
| Абдрахманова Р.Р. | МКУ «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» башлыгы урынбасары |
| Эшче төркем сәркатибе | |
| Рамазанов Ф.З. | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ методисты |
| Эшче төркем әгъзалары | |
| Нуриев Д.Д. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» ӨББ МБУ директоры |
| Кадыйрова М.Н. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Балалар сәнгать мәктәбе" ӨББ МБУ |